**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында**
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

18 октябрь, 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ульянково авыл җирлегенең Ульянково торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Ульянково авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

а) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ульянково авыл җирлеге башлыгы Ф.А.Сундурова